**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ТУЙМЕТКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул.Школьная ,дом 4, с.Туйметкино, 423108

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ТУЙМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Мәктәп урамы, 4 нче йорт, Туймәт авылы, 423108

тел./факс email: 8-(84396) 3-72-90. Tuy.Cmn.2@tatar.ru

**16.06.2021** **№27**

# Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Советы КАРАРЫ

«Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Советының 2012 елның 27 декабрендәге 38 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге территориясендә «Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен» раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Советы карары проекты

Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Советының 2012 елның 27 декабрендәге 38 номерлы карары белән (2018 елның 29 ноябрендәге 99 номерлы үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлегенең «Җирлектән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре» нә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 30 статьясындагы 1.2 пунктын «Җир кишәрлекләрен һәм капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән файдалануның иң чик параметрлары, җир кишәрлеге күләме» яңа редакциядә бәян итәргә:

«Җир кишәрлекләренең тәкъдим ителгән күләме:

- җир кишәрлегенең минималь мәйданы 1000 кв. м. (элек бирелгән җир кишәрлекләренә кагылмый);

- җир кишәрлегенең максималь мәйданы 2000 кв. м. (элек бирелгән җир кишәрлекләренә кагылмый)».

2. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Советының 2012 елның 27 декабрендәге 38 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге территориясендә «Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен» раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Советы карары проектын гавами тыңлауларга чыгарырга.

3. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Советының 2012 елның 27 декабрендәге 38 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге территориясендә «Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен» раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрергә 2021 елның 1 июлендә сәгать 14.00, түбәндәге адрес буенча: 423108, Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы, Туймәт авылы, Школьная урамы, 4.

4. Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Советына ачык тыңлаулар үткәрүне, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

5. Торак-коммуналь хуҗалык, төзелеш, җир төзелеше, авыл хуҗалыгы, экология һәм халык иминлеге буенча даими комиссиясенә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Советының халык алдында әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып карар проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Советы утырышына карауга кертергә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Туймәт авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе А.Б. Кәримов